МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.06.2016 г.Казань № 176

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277нче боерыгы белән расланган Кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Законнарга туры китерү максатларында б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277нче боерыгы белән расланган Кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган түбәндә теркәлгән үзгәрешләрне расларга (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2014 елның 8 августындагы 280нче, 2015 елның 19 мартындагы 134нче, 2015 елның 3 июлендәге 317нче, 2016 елның 16 мартындагы 70нче боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән бергә) (алга таба – Административ регламент).

2. Дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән эш итү бүлегенә (И.С.Сәгыйтов) әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сайтына урнаштырылуын тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне министр урынбасары А.Д.Шәмсиевкә йөкләргә.

Министр в.б. – беренче урынбасар,
Эшкуарлыкны үстерү департаменты директоры Р.Р. Сибгатуллин

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы
боерыгы белән расланган
02.06.2016 № 176

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277нче боерыгы белән расланган Кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Административ регламентның 2нче бүлегендә:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасының 2.4 пунктының җиденче һәм сигезенче абзацларын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы ведомствоара мәгълүмати эш итү кысаларында документлар һәм (яисә) мәгълүмат алыну кирәклеге очрагында туктатыла, ләкин ун эш көненнән дә күбрәккә түгел. Кабат туктатылу рөхсәт ителми.

Лицензияләр реестры Министрлыкның рәсми сайтында ачык карауга урнаштырылган.»;

«Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгеләүче норматив акт» графасының 2.4 пунктын түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац белән тулыландырырга:

«294-ФЗ номерлы Федераль законның 13нче маддәсе 2нче өлеше».

Административ регламентның 1-4нче Кушымталарын түбәндәге эчтәлектәге соңгы абзацлар белән тулыландырырга:

«Шәхси мәгълүматны эшкәртүгә аны имзалаган көннән алып, язма формада кире алган көнгә кадәр ризалыгымны бирәм (шәхси эшкуарлар өчен) ________________________________________________________________________________________

(Ф.И.О., имза)».